Шәһәр тибындагы Җәлил поселогы Советы

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

04.03.2019 ел №2

Сарман муниципаль районы «Җәлил шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге башлыгының «Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының муниципаль вазыйфаларын биләүче затларның һәм Җәлил шәһәр тибындагы поселогы муниципаль хезмәткәрләренең вазыйфаи хәлләренә яисә аларның хезмәт (вазыйфаи) бурычларын үтәүгә бәйле рәвештә бүләк алу, бүләк тапшыру һәм бәяләү, аларны гамәлгә ашыру (сатып алу) һәм аны гамәлгә ашырудан кергән акчаларны күчерү тәртибе турында» 2014 елның 12 мартындагы 3 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында»

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы Федераль законның 2 һәм 28 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында 2018 елның 30 октябрендәге 387-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә», Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы «Җәлил шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге Уставы белән карар бирәм:

1. Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы «Җәлил шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге башлыгының «Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының муниципаль вазыйфаларын биләүче затларның һәм «Җәлил шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге муниципаль хезмәткәрләренең вазыйфаи хәлләренә яисә аларның хезмәт (вазыйфаи) бурычларын үтәүгә бәйле рәвештә бүләк алуы, бүләк тапшыру һәм бәяләү, аны гамәлгә ашыру (сатып алу) һәм аны гамәлгә ашырудан кергән акчаларны күчерү тәртибе турында» 2014 елның 12 мартындагы 3 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2 пунктның икенче абзацында «хәлиткеч тавыш хокукы белән» сүзләрен «комиссиядә даими (штат) нигездә эшләүче хәлиткеч тавыш хокукы белән» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны махсус мәгълүмати стендларда халыкка игълан итәргә һәм «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU), «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы «Сарман муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында урнаштырырга.

3.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үзем артыннан калдырам.

«Җәлил шәһәр тибындагы поселогы»
муниципаль берәмлеге башлыгы Р.Ә. Кәримов